**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 6 ноябрь № 844

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет һәм балаларга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет бирү тәртибен раслау турында» 2005 ел, 7 апрель, 161 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 28 декабрь, 628 нче; 2006 ел, 22 март, 117 нче; 2006 ел, 5 июль, 341 нче; 2006 ел, 2 октябрь, 490 нчы; 2007 ел, 21 март, 98 нче; 2007 ел, 17 декабрь, 726 нчы; 2008 ел, 5 июнь, 373 нче; 2008 ел, 14 ноябрь, 806 нчы; 2008 ел, 18 декабрь, 899 нчы; 2009 ел, 20 апрель, 239 нчы; 2009 ел, 28 декабрь, 897 нче; 2010 ел, 30 декабрь, 1135 нче; 2011 ел, 4 август, 633 нче; 2012 ел, 6 апрель, 279 нчы; 2012 ел, 17 сентябрь, 772 нче; 2013 ел, 19 гыйнвар, 22 нче; 2013 ел, 26 декабрь, 1062 нче; 2013 ел, 28 декабрь, 1074 нче; 2014 ел, 26 декабрь, 1036 нчы; 2015 ел, 30 ноябрь, 904 нче; 2016 ел, 27 декабрь, 1010 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет һәм балаларга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

10 нчы пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары бу Тәртипнең 3 нче пунктында күрсәтелгән гражданнарга сатылган транспортта йөрү өчен билетлар һәм балаларга транспортта йөрү өчен билетлар турындагы мәгълүматны Социаль хезмәтләр белән тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә, һәм Социаль хезмәтләр белән тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы операторы тарафыннан билгеләнгән формат нигезендә алып баруны тәэмин итә.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ташламалы транспорт кушымтасы булган электрон карталар һәм транспорт кушымтасы булган электрон карталар бирү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 2 июль, 574 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«автоматлаштырылган система операторы белән берлектә, ташламалы транспорт кушымтасы булган электрон карталарның транспорт ресурсын тулыландыру турындагы мәгълүматны Социаль хезмәтләр белән тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә, һәм Социаль хезмәтләр белән тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы операторы тарафыннан билгеләнгән формат нигезендә алып баруны тәэмин итүне.»;

әлеге карар белән расланган ташламалы транспорт кушымтасы булган электрон карталар һәм транспорт кушымтасы булган электрон карталар бирү тәртибендәге 3 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«ташламалы транспорт кушымтасы булган электрон карталарның транспорт ресурсын тулыландыру турындагы мәгълүматны электрон карта тулыландырылган айның 20 сенә кадәр Яр Чаллы, Әлмәт, Түбән Кама һәм Зеленодольск шәһәрләре муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетларына тапшыруны.».

3. Бу карар 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\844.doc